КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 21 февраль г.Казань № 124

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Иң яхшы муниципаль практика» бөтенроссия конкурсының республика этабын үткәрү турында» 2017 ел, 27 май, 313 нче карары белән расланган «Иң яхшы муниципаль практика» бөтенроссия конкурсының республика этабын оештыру һәм үткәрү буенча республика комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Иң яхшы муниципаль практика» бөтенроссия конкурсының республика этабын үткәрү турында» 2017 ел, 27 май, 313 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 24 гыйнвар, 32 нче, 2018 ел, 20 июнь, 501 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Иң яхшы муниципаль практика» бөтенроссия конкурсының республика этабын оештыру һәм үткәрү буенча республика комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

конкурс комиссиясе составыннан М.Г.Әхмәтовны, Р.И.Вәлиевны, М.Г.Галиевны, И.Ә.Фәйзуллинны, А.А.Фоминны, Р.А.Шәйхетдиновны чыгарырга;
конкурс комиссиясе составына кертергә:

| | |
|---|---|
| Вәлиева Зилә Рәхимҗан кызын | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисен (килешү буенча) |
| Җәббаров Марат Азат улын | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарын – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрын |

| | |
|---|---|
| Сәлимгәрәев Айдар Сәитгәрәй улын | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесен |
| Хәйруллин Айрат Ринат улын | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрын |
| Хәнифов Фәрит Мөдәрис улын | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрын |
| Шәфигуллин Лотфулла Нурислам улын | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшмәкәрлек комитеты рәисен (килешү буенча); |

Зарипов Айрат Ринат улы вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисен (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин